ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

# КАРАР

2022 елның «15» декабреннән № 18

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге-45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым җыю тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю тәртибе турында» 20.11.2018 ел, №28 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г. Гайфетдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгының
2022 елның 15 декабреннән 18 нче
номерлы карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлегендә 18 яше тулган, Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, гражданнарның җыенында (җирле референдумда) катнашуларына һәм алар тавыш биргән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә үзара салым кертү турында карар кабул ителгәннән соң, гражданнарның үзара салым акчалары 31 мартка кадәр түләнә.

3. Үзара салым буенча бер тапкыр түләүдән азат ителгән затларның категорияләре гражданнар җыенында билгеләнә һәм кабул ителә.

4. Нигезле сәбәпләр (авыру, озак вакытлы командировка, отпуск) вакытында түли алмаган түләүчеләр Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетына бер тапкыр түләнүне кичектерү турында гариза белән мөрәҗәгать итә алалар. Кичектерү өч айга бирелә.

5. Бер тапкыр бирелә торган түләүне түләү турындагы хәбәр бланкы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару юлы белән гражданнарга җиткерелә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru, шулай ук тапшыру юлы белән яки почта элемтәсе аша бирелә.

Хәбәрдә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү буенча түләү реквизитлары, бер тапкыр тулы яки киметелгән күләмдә түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар түләүләре физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша, Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша күчерелә: https://uslugi.tatarstan.ru/.

8. Түләү фактын раслау булып Керем касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Әлеге Тәртиптә билгеләнгән срокта түләнмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге торак
пунктларында гражданнарның
үзара сәлым акчаларын
җыю тәртибенә кушымта

БЕЛДЕРМӘ № ___
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында

Түләүче Ф.И.А.и.________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
___________________________________________________нигезендә
Сезгә ________ га кадәр _________________________ чараларны тормышка ашыру өчен ____________ сум бер тапкыр түләү түләргә кирәк,
түбәндәге реквизитлар буенча: ______________________________________________

Алучы банкы:

БИК_______________________________________________________
Сч. № _____________________________________________________
Алучы Сч. № _________________________________________________
ИНН_______________ КПП______________________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________________________
Түләү билгеләмәсе __________________________________________
Җитәкче __________________ _______________________________
П.У. (имза) (имза аңлатмасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - -
Белдермә (Белдерү) № __________________
Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү суммасы турында ________________ сум.

Түләүче Ф.И.А.и.__________________________________________________
Адресы: _______________________________________________________________

Алды «__» ________________ 20__ ел. ________________________________________
(түләүче имзасы)

Искәрмә. Хәбәр түләүчегә шәхсән тапшырылса, тармак тутырыла һәм Зирекле авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.